105нче балалар бакчасының укытучы-логопеды Пыгина Эльмира Равильевнаның дидактик уены “Тылсымлы чәчәк”



Максат: балаларның сүз байлыгын арттыру, сузык һәм тартык авазларны кабатлау, авазларның дөрес итеп әйтелүенә ирешү, сүзләрне иҗекләргә бүлү һәм сүздәге авазларны санау өстендә эшне дәвам итү, схема ярдәмендә сүзләрдә авазның урынын билгеләү, балаларның фонематик ишетү сәләтен үстерү, грамотага өйрәтүгә әзерлек, предметларны классификацияләү буенча белемнәрен ныгыту.

Уенны берничә ысул белән уйнап була.

<u>Беренче ысул:</u> Чәчәк уртасына А хәрефе куела. А авазына башлана торган рәсемнәрне табып, чәчәк таҗларына урнаштырырга тәкъдим ителә.



Икенче ысул: чәчәк уртасына биш саны бирелә. Биш аваздан торган сүзләрнең рәсемнәрен чәчәк таҗларына куярга тәкъдим ителә.



Өченче ысул: чәчәк уртасына ике саны бирелә. Ике иҗектән торган сүзләрнең рәсемнәрен чәчәк таҗларына куярга тәкьдим ителә.



Дүртенче ысул: балаларга нинди булса да аваз бирелә һәм шул аваз кергән схемасы бирелә (аваз сүзнең башында, уртасында һәм ахырында була ала), схема буенча кирәкле рәсемнәрне табып, чәчәк таҗларына урнаштырырга тәкьдим ителә.




ә


К

<u>Бишенче ысул:</u> предметларны гомумиләштерүче сүз чәчәк уртасаны куела, ә чәчәк таҗларына балалар кирәкле рәсемнәрне табып урнаштыралар (җиләк-җимешләр, уенчыклар, йорт һәм кыргый хайваннар һ.б.).



ИГЪТИБАРЫГЫЗ

ӨЧЕН  РЭХМӘТ !